ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.07.2024 с.Старое Дрожжаное № 297

«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 9 сентябрендәге 679 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 04 февралендәге 100 номерлы карары нигезендә, Чүпрәле муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» 2013 елның 09 сентябрендәге 679 номерлы (31.01.2014 № 59, 12.02.2014 № 88, 10.02.2017 № 78, 24.08.2017 № 463, 19.10.2017 № 591, 21.12.2017 № 707, 22.08.2019 № 364, 06.04.2023 № 161 ред.) карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибенә, 2 нче бүлекнең 2.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге «к» пунктчасы белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«к) күп балалы гаиләләргә һәр балага туу турында таныклыкларның күчермәсен раслаучы документлар буларак.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән законлы көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.Ф. Җәләловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов